Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Ерсубайкино авыл Советы

КАРАРЫ

03 июнь 2022 ел № 45

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авыл Советының 2014 елның 05 ноябрендә кабул ителгән 123 номерлы « Ерсубайкино авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук Ерсубайкино авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Ерсубайкино авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авыл Советының 2014 елның 05 ноябрендә кабул ителгән 123 номерлы « Ерсубайкино авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук Ерсубайкино авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмә хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

каpаргa 1 нче кушымтада:

6 пунктның в) пунктчасында «акцияләрен» сүзен төшереп калдырырга;

13 пунктта «акцияләрен» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Ерсубайкино авылы, Совет урамы, 11 нче йорт, Яңа Елань авылы, Үзәк урам, 35 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Ерсубайкино
авыл җирлеге башлыгы Е.Г.Николаева